**Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Федоровка авыл җирлегенең Федоровка торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында гражданнар җыены карары**

**13 .12. 2023** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Федоровка авыл җирлегенең Федоровка торак пунктында гражданнар җыены:

1. 2024 елда Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Федоровка авыл җирлеге Федоровка торак пункты территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, I төркем инвалидлардан тыш, 1000 (бер мең) сум күләмендә гражданнарның үзара салым салуын кертергә, төрмәдә утыручы гражданнар, махсус хәрби операциядә катнашучылар (контракт буенча хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгәннәр, ирекleләр) һәм аларның гаилә әгъзалары, атап әйткәндә: ата-аналар, ир белән хатын, балигъ булган балалар; гаилә әгъзалары, атап әйткәндә: ата-аналар, ир белән хатын, балигъ булган балалар, һәлак булган махсус хәрби операциядә катнашучылар (контракт буенча хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгәннәр, ирекләләр).

2. Гражданнарның үзара салым акчаларын түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү:

-Федоровка торак пунктында 1 Май урамы, Ленин урамы, Гагарин урамы буенча вак таш, ком сатып алу, нигез салу, ташу, салу, эш өчен түләү, хезмәт күрсәтү сметасына ярашлы рәвештә юл-урам челтәрен норматив хәлгә китерү (смета буенча поселок эчендәге юлларны ремонтлау).

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Федоровка авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (https://tetushi.tatarstan.ru/) һәм «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында " (https://pravo.tatarstan.ru/) урнаштырырга.

**Җитәкче** **М.Ю. Никонорова**